**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Поповка авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 13** **10.12.2020 ел**

**2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1 статья

1. 2021 елга Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2925,1 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2925,1 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты дефицитын 0 мең сум күләмендә.

2. 2022 һәм 2023 елларга Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2022 елга 2958,9 мең сум, 2023 елга 2982,3мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2022 елга 2958,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 74,3 мең сум һәм 2023 елга 2982,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 146,7 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум күләмендә.

3. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең 2022 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең 2023 елның 1

гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең 2024 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга;

3 статья

Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетында 2021 елга, 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 кушымта нигезендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. 2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 кушымта нигезендә расларга.

2. 2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 6 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2021 елга 0 мең сум күләмендә, 2022 елга 0 мең сум күләмендә, 2023 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

6 статья

1. Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетыннан вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру буенча төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга:

- Поповка авыл җирлегендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча 2021 елга 1036,0 мең сум, 2022 елга 1045,5 мең сум, 2023 елга 1055,1 мең сум күләмендә;

2. 2021-2023 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7 статья

Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләрне 2021 елда – 1140,3 мең сум, 2022

елда – 1172,9 мең сум, 2023 елда 1192,3 мең сум күләмендә расларга.

8 статья

Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетында Зәй муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләр күләмнәрен расларга:

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр2021 елда – 99,8 мең сум, 2022 елда - 101,0 мең сум, 2023 елда - 105,0 мең сум.

9 статья

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына 2021 елга Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә 27,6 мең сум күләмендә, 2022 елга 42,2 мең сум күләмендә, 2023 елга 43,0 мең сум күләмендә күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетына Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге бюджетыннан бюджетара субсидияләр ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

10 статья

Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешү нигезендә Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

12 статья

Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүгә муниципаль контрактларның 2020 елда түләнергә тиешле шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә 2021 елда Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

13 статья

Әлеге карарны җирле массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/rus/begishevskoe.htm) адресы буенча урнаштырырга .

14 статья

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Поповка авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **И.А.Амерханов**